**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «14» декабреннән № 39-313

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының
2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына
социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К. Исхакованың Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы турындагы мәгълүматны тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К. Исхакованың Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразын хупларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәгеләр буенча эшне активлаштырырга тәкъдим итәргә:

- инвестиция активлыгын стимуллаштыру;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә, федераль ташламалы кредитлауны, ташламалы республика микрозаймнарын, поручительлекләрне һәм турыдан-туры булмаган финанс ярдәме чараларын да кертеп, федераль һәм республика ярдәме чаралары комплексын гамәлгә ашыру исәбенә яңа шартларга яраклаштыру, шулай ук сәнәгать паркын үстерү;
- милли проектларны һәм муниципаль программаларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны дәвам итү;
- халыкның керемнәрен һәм тормыш сыйфатын күтәрүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;

- халыкның мәшгульлеген, шул исәптән предприятиеләр һәм оешмаларның тиешле ярдәм чараларында катнашуын саклап калу.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, барлык төр милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы В.М. Козлов